| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2025 Олы Кайбыч ав. № 8

Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнары өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Субсидияләр биргәндә аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып субсидияләр бирү турындагы шартнамәләргә (килешүләргә) һәм шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) керүче товарлар җитештерү (сату) , эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча товар китерүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның һәм субсидия алучыларның (устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашкан дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән

шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерция оешмаларыннан тыш,) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 бүлегендә каралган тикшерүләрне муниципаль финанс контроле органнары - субсидия бирә торган бюджет акчаларының төп бүлүчесе - башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашыруга ризалыгы тора.».

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб - адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда һәм ttps://bkaybic -kaybici.tatarstan.ru/ веб - адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын үтәүче И.Ф.Әхмәтов